**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктның икенче абзацында «, шулай ук әлеге премияне түләүнең тәртибен һәм шартларын расларга» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турында нигезләмәдә:

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Премия лауреатына диплом һәм почет билгесе тапшырыла, шулай ук акчалата бүләк бирелә.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Диплом һәм почет билгесе Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан тантаналы шартларда тапшырыла. Акчалата бүләкне тапшыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләгән тәртиптә һәм шартларда башкарыла.»;

в) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты турында нигезләмәнең 4 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) бүләкләү документларын рәсмиләштерү, дипломны һәм почет билгесен тапшыруны оештыру;».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-778